**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 август № 563

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы гражданнарына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 ел, 2 ноябрь, ТРЗ-73 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 2 февраль, 69 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 февраль, 103 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы кысаларында гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга (теркәлгән).»;

әлеге карарга Түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы кысаларында гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне өстәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче, 2015 ел, 11 март, 144 нче, 2016 ел, 24 март, 164 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә 4 нче кушымтага, 1 пунктның «л» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«л) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар – җирле үзидарә органы яки гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм гадәттән тыш хәл барлыкка килгән урында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия биргән белешмә, шулай ук:

1) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән аның һәлакәте (үлеме) көнендә теркәлгән никахлы булган ире (хатыны) – үлү турында таныклык, яисә җинаять эше кузгатудан баш тарту (эш буенча производствоны туктату) турында карар, яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән аның һәлакәте (үлеме) көнендә теркәлгән никахлы булган ире (хатыны) үлү фактын билгеләү турында суд карары күчермәсе, шулай ук никахны теркәү турында таныклык;

2) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең балалары – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең балалары туу турында таныклык яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән балаларның туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсе;

3) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең әти-әнисе – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган затның туу турында таныклыгы, яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән әти-әнисенең туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсе;

4) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булган яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм ала торган затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә асрама дип танылган бүтән затлар – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук затның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булуын яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм алуын раслый торган документ, яисә затның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булуын яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм алуын раслый торган суд карары күчермәсе;

5) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлекләренә зарар килгән гражданнар – гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлекләренә зарар килүне раслый торган медицина документлары яки бүтән документлар;

6) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калган яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалткан кешеләр – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калуын яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалтуын раслый торган

документ яки гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калуын яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалту фактын раслый торган суд карары күчермәсе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2013 ел, 2 февраль, 69 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 15 август, 563 нче
карары редакциясендә)

**Түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы кысаларында гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль закон), «Татарстан Республикасы гражданнарына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – «Татарстан Республикасы гражданнарына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Закон) нигезендә эшләнде һәм түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы кысаларында гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү тәртибен һәм шартларын җайга сала.

2. Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән түбәндәге гражданнар түләүсез юридик ярдәм алуга хокуклы:

1) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән аның һәлакәте (үлеме) көнендә теркәлгән никахлы булган ире (хатыны);

2) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең балалары;

3) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең әти-әнисе;

4) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булган яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм ала торган затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә асрама дип танылган бүтән затлар;

5) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлекләренә зарар килгән гражданнар;

6) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калган яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалткан гражданнар.

3. Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар түләүсез юридик ярдәм алуга хокукларын шәхсән үзләре яки вәкилләре аша тормышка ашыра ала.

4. Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы

катнашучылары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында каралган документлар нигезендә кабул ителә.

5. Түләүсез юридик ярдәм алу өчен гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар түбәндәге документларны тапшыра:

1) кирәкле түләүсез юридик ярдәмнең төрен һәм вәкаләтле орган раслаган форма буенча аны күрсәтү нигезләрен күрсәтеп, түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында гариза;

2) шәхесне таныклый торган документ;

3) җирле үзидарә органы яки гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм гадәттән тыш хәл барлыкка килгән урында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия биргән белешмә;

4) түләүсез юридик ярдәм алуга хокуклы гражданнар категорияләренең берсенә керүне раслый торган документ:

а) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән аның һәлакәте (үлеме) көнендә теркәлгән никахлы булган ире (хатыны) – үлү турында таныклык, яисә җинаять эше кузгатудан баш тарту (эш буенча производствоны туктату) турында карар, яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән аның һәлакәте (үлеме) көнендә теркәлгән никахлы булган ире (хатыны) үлү фактын билгеләү турында суд карары күчермәсе (алга таба – гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә гражданның һәлакәте (үлеме) фактын раслый торган документ), шулай ук никахны теркәү турында таныклык;

б) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең балалары – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең балалары туу турында таныклык яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән балаларның туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсе;

в) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең әти-әнисе – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган затның туу турында таныклыгы, яисә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кеше белән әти-әнисенең туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсе;

г) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булган яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм ала торган затлар, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә асрама дип танылган бүтән затлар – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булу (үлү) фактын раслый торган документ, шулай ук затның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булуын яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм алуын раслый торган документ, яисә затның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) кешенең тулысынча каравында булуын яки аңардан үзләренең яшәүләре өчен даими һәм төп чыганак булган ярдәм алуын раслый торган суд карары күчермәсе;

д) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлекләренә зарар килгән гражданнар – гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә сәламәтлекләренә зарар килүне раслый торган медицина документлары яки бүтән документлар;

е) гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калган яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалткан кешеләр – гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калуын яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалтуын раслый торган документ яки гражданның гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә торак урынсыз калуын яисә бүтән мөлкәтләрен тулысынча яки өлешчә яисә документларын югалту фактын раслый торган суд карары күчермәсе.

Түләүсез юридик ярдәм алу өчен граждан шәхсән үзе мөрәҗәгать итә алмаган очракта әлеге пунктта күрсәтелгән документлардан тыш вәкилнең шәхесен таныклый торган документ, шулай ук вәкилнең хокукларын раслаган ышанычнамә яки бүтән документ күрсәтелә.

6. Түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы катнашучылары Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга үз компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законда, «Татарстан Республикасы гражданнарына түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Законда каралган төрләрдә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

7. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтелми:

1) әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә карамаган граждан түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә;

2) граждан «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 20 статьясында билгеләнгән түләүсез юридик ярдәм күрсәтү очракларына карамаган түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә;

3) Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән очракларда.

8. Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта түләүсез юридик ярдәмнең дәүләт системасы катнашучысы, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итә.

9. Баш тарту турында хәбәр итү кәгазе карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә мондый баш тарту кәгазе гражданга җибәрелү фактын раслау мөмкин булган теләсә кайсы ысул белән җибәрелә.